**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8556**
**21.10.2025**

«2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәрендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын тормышка ашыру чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында каралган акчалар хисабына 250 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2026 елда – 50 мең сум; 2027 елда – 50 мең сум; 2028 елда – 50 мең сум; 2029 елда – 50 мең сум; 2030 елда – 50 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль

берәмлегенең рәсми сайтында https://nabchelny.ru адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 21 октябрендәге
8556 номерлы карарына
кушымта

«2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасы

1 бүлек. «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба - программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаны төп эшләүчеләр һәм башкаручылар | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе |
| Программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын күтәрү |
| Программаның бурычлары | 1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсен тарату һәм кертү.<br>2. Хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын тормышка ашыру.<br>3. Социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне иртәрәк ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм камилләштерү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2026-2030 еллар |

<table>
<tr><td rowspan="9">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td colspan="7">Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 250 мең сум тәшкил итә.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="6">Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум</td></tr>
<tr><td>2026 (мең сум)</td><td>2027 (мең сум)</td><td>2028 (мең сум)</td><td>2029 (мең сум)</td><td>2030 (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>250</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>250</td></tr>
<tr><td colspan="7"></td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="7">Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2030 елда түбәндәгеләр күздә тотыла:<br>1) балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне киметү;<br>2) профилактик исәптә торган, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның санын арттыру;<br>3) социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдә тормыш сыйфатын яхшырту;<br>4) социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган, күп балалы гаиләләрдә яшәүче, эшкә урнаштырылган балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) санын арттыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы</td><td colspan="7">Программаны тормышка ашыруга контрольне Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Программа Яр Чаллы шәһәрендәге җинаятьчелекнең гомуми торышын исәпкә алып эшләнде.

2025 елның 8 ае йомгаклары буенча Яр Чаллы шәһәре буенча яшүсмерләр җинаятьчелеге 21,6% ка (60 тан 73 кә кадәр) арткан. Яшүсмерләр җинаятьчелегенең чагыштырма авырлыгы 5% тәшкил итә.

Җинаятьләрдә балигъ булмаган катнашучылар саны 5,2% ка (57 дән 60 ка кадәр) арткан. Балигъ булмаганнар тарафыннан күп эпизодлы һәм серияле җинаятьләр кылу очраклары да бар. 2025 елның 8 аенда 60 балигъ булмаган бала 73 җинаять кылуда катнашкан, шулардан күп эпизодлы һәм серияле 6 җинаять эше - 22 эпизодлы, 51 җинаять - берешәр.

Яшүсмерләр җинаятьчелеген анализлау күрсәткәнчә, нигездә балигъ булмаганнар табыш алу юнәлешендәге җинаятьләр кыла (җинаятьләрнең гомуми санының якынча 75% ы), аларның күбесе сәүдә нокталарыннан урлаулар.

2025 елның 8 аенда катнаш төркемнәрдә 14 балигъ булмаган бала катнашында 18 җинаять кылынган, катнаш төркемнәрдә балигъ булмаганнар тарафыннан җинаятьләр кылуның кимүе күзәтелә.

Яшүсмерләр җинаятьчелеген кисәтү буенча иң нәтиҗәле эш формаларының берсе булып җинаятьләр кылуга бирелүчән балигъ булмаганнарны үз вакытында ачыклау, алга

таба аларны «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә, ябык типтагы махсус уку йортларында изоляцияләү тора. 2025 елның 8 аенда балигъ булмаганнар тарафыннан җинаять өчен җәза бирү яшенә җиткәнче 22 иҗтимагый - куркыныч җинаять кылынган, анда 24 балигъ булмаган бала катнашкан. 3 балигъ булмаган бала «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә һәм 1 балигъ булмаган бала ябык типтагы махсус учреждениегә урнаштырылган.

2025 елның 8 аенда 38 профилактик рейд үткәрелгән, алар барышында төнге вакытта урамнарда һәм җәмәгать урыннарында ата-аналары яки аларны алыштыручы затлар озатуыннан башка 213 балигъ булмаган бала тоткарланган.

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча үткәрелә торган эш шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртыла. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре балигъ булмаганнарга анда йөрү тыелган яки чикләнгән урыннарны тикшерү буенча рейдларда катнашалар.

Шәһәрдә җинаятьчелеккә каршы торуның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен хокук бозуларны профилактикалау субъектларының бу юнәлештә бердәм эшләүләрен дәвам итү һәм эш гамәлләрен координацияләү таләп ителә.

Югарыда күрсәтелгән фактлар Яр Чаллы шәһәрендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау проблемаларын хәл итүдә программалы-максатчан якын килүне куллану кирәклеген шарт итеп куя.

Программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык булып кала.

## 3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаны тормышка ашыру 5 елга – 2026-2030 елларга исәпләнә.

Программаның максаты булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын күтәрү тора.

Программаның бурычлары:

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсен тарату һәм кертү;
- хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын тормышка ашыру;
- социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне иртәрәк ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм камилләштерү.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган индикаторлар

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим ителә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның | N - сан | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | саны, берәмлек | | идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегенең статистик мәгълүматлары |
| 2. | Җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | Днов = НОВ / НСУ х 100, монда<br>Днов – җинаять кылган, җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НОВ - җинаять кылган, җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның саны;<br>НСУ – полициянең профилактик исәпләрендә (алга таба – ППИ) торган һәм социаль куркыныч хәлдә (алга таба – СКХ) булган балигъ булмаганнарның саны | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең статистик мәгълүматлары |
| 3. | Профилактик исәпләрдә торган, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның саны, процент | Днз = НЗ / НСУ х 100, монда<br>Днз - социаль куркыныч хәлдә булган, эчке эшләр органнарында профилактик исәпләрдә һәм мәктәпнең эчке контролендә торучы, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НЗ - социаль куркыныч хәлдә булган, эчке эшләр органнарында профилактик исәпләрдә һәм мәктәпнең эчке контролендә торучы, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның саны;<br>НСУ - социаль куркыныч хәлдә булган, эчке эшләр органнарында профилактик исәпләрдә һәм мәктәпнең эчке контролендә торучы балигъ булмаганнарның саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе хисаплары |
| 4. | Социаль куркыныч хәлдә булган, эшкә урнаштырылган балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) өлеше | Дтн = ТН / СОП х 100, монда<br>Дтн - социаль куркыныч хәлдә булган, эшкә урнаштырылган балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) өлеше;<br>ТН - социаль куркыныч хәлдә булган, эшкә урнаштырылган балигъ булмаганнарның саны;<br>СОП - социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарның саны | Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе департаменты хисабы |
| 5. | Укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр өлеше, процент | Дбыт = ОШ / Ш х 100, монда<br>Дбыт - укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр өлеше;<br>ОШ – укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр саны;<br>Ш – укучы балалары булган гаиләләр саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе хисабы |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2026-2030 елларга программаны финанслау күләме 250 мең сум тәшкил итә: 2026 елда – 50 мең сум; 2027 елда – 50 мең сум; 2028 елда – 50 мең сум; 2029 елда – 50 мең сум; 2030 елда – 50 мең сум.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә түбәндәгеләр хисабына ирешеләчәк:

- балигъ булмаганнар арасында теркәлгән җинаятьләрнең санын киметү;
- профилактик исәпләрдә торган яшүсмерләр тарафыннан кылынган җинаятьләрнең санын киметү;
- профилактик исәпләрдә торган, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның санын арттыру.

7 бүлек. «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасының программа чаралары

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын күтәрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсен тарату һәм кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. Балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышларын, балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикау мәсьәләләре буенча семинарлар, киңәшмәләр оештыру һәм үткәрү | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (килешү буенча), Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2026-2030 | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 90 | 85 | 80 | 80 | 80 | 80 | - | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча иң яхшы белем бирү учреждениесе конкурсын оештыру һәм үткәрү | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (килешү буенча), Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2030 елларның җәйге чоры | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 90 | 85 | 80 | 80 | 80 | 80 | | | - | | |
| 3. «Балигъ булмаган яшүсмернең иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсын оештыру һәм үткәрү | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (килешү буенча) | 2026-2030 | Җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | 70 | 75 | 75 | 75 | 75 | 75 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| 4. «Ата-аналар университеты» оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2030 | Профилактик исәпләрдә торган, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | 74 | 75 | 78 | 80 | 80 | 80 | | | - | | |
| 5. Шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма | 2026-2030 | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 90 | 85 | 80 | 80 | 80 | 80 | | | - | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төркемнәрдә балигъ булмаганнар арасын да хокук бозуларны профилактикалау буенча материаллар урнаштыру | комитетның районнар хакимиятләре | | | | | | | | | |
| 2 бурыч. Хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауга юнәлтелгән чаралар комплексын тормышка ашыру | | | | | | | | | | |
| 6. Профилактик исәпләрдә торган балигъ булмаганнар өчен профильле сменалар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2030 | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 90 | 85 | 80 | 80 | 80 | 80 | - |
| 7. Социаль куркыныч хәлдә булган, эчке эшләр органнарында профилактик исәпләрдә һәм мәктәпнең эчке контролендә торучы балигъ булмаганнарны өстәмә белем бирүгә җәлеп итүне оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2026-2030 | Профилактик исәпләрдә торган, өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | 74 | 75 | 78 | 80 | 80 | 80 | - |
| 3 бурыч. Социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне иртәрәк ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм камилләштерү | | | | | | | | | | |
| 8. Ел саен уздырыла торган «Яшүсмер» | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ | 2026-2030 елларның җәйге чоры | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның | 90 | 85 | 80 | 80 | 80 | 80 | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ведомствоара профилактика операциясен үткәрү | булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (килешү буенча), Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге | | саны, берәмлек | | | | | | | |
| 9. Ел саен уздырыла торган «КӨНКҮРЕШ» операциясен оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2030 | Укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр өлеше, процент | 85 | 86 | 87 | 87 | 87 | 87 | - |
| 10. «Татарстан Республикасында социаль-куркыныч хәлдә булган балаларны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу һәм мониторинг» мәгълүмат системасындагы профилактика системасы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (килешү буенча), Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр | 2026-2030 | Укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр өлеше, процент | 85 | 86 | 87 | 87 | 87 | 87 | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| субъектларының эш нәтиҗәлелеген мониторинглауны оештыру | белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге | | | | | | | | | | | | | |
| 11. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны каникулда һәм укудан тыш вакытларда эшкә урнаштыруны оештыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2030 | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 90 | 85 | 80 | 80 | 80 | 80 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева